**Республика Татарстан**
**Глава Большенуркеевского**
**сельского поселения**
**Сармановского муниципального**
**района**

Ул. Школьная, д. 32, с. Большое
Нуркеево Сармановский район, 423372

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль**
**районының Зур Нөркәй**
**авыл җирлеге**
**башлыгы**

Мәктәп урамы, 32 нче йорт, Зур
Нөркәй авылы, Сарман районы, 423372

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03 ноябрь 2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй авылы өлешендә 2021 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Зур Нөркәй авылы, С.Рафиков урамы, 32 нче йорт адресы буенча урнашкан Зур Нөркәй авылы мәдәният йорты бинасында 13 ноябренә 13.00 сәгатьтә Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй авылында 2021 нче елның гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: 1 төркем инвалидлар, көндезге уку йортлары студентлары, дүрт һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрдән кала, Зур Нөркәй авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) Зур Нөркәй авылында бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр алу (Сабантуй, 9 Май, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне);

2) махсуслаштырылган техниканы карап тоту - «Беларус-82.1 " тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәте өчен түләү);

2) махсуслаштырылган техниканы карап тоту - «Беларус-82.1 " тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәте өчен түләү);

3) Зур Нөркәй урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урамнарны яктырту яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырту челтәрләрен карап тоту һәм аларга техник хезмәт күрсәтү);

4) Зур Нөркәйдә төзекләндерү буенча хезмәт күрсәтүчеләргә түләү (үлән чабу);

5) Зур Нөркәй авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарны вакытлыча җыю;

6) некрологларны район «Сарман" газетасында бастырып чыгару»;

7) җирлекнең торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны грейдлау;

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Зур Нөркәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында, http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Сарман муниципаль районы

Зур Нөркәй авыл җирлеге Башлыгы Р.М.Гайсин